Бәшәров Р. Г.

# Җәй кызы

## Шигъри әлифба

АТ йомшак иренен
Тидерде дә солыга,
Ашап туйгач, баш чөеп
Чыгып чапты болынга.

ӘРЛӘН карый еракка,
Ак ат утлаган якка.
Ат чаба. Үлән чыгы
Җем-җем итә тоякта.

БАЛ КОРТЛАРЫ безелдәп
Очып-очып килделәр:
— Без-з-з, без-з-з, таныйсыз-з-змы,
Без-з-з бит нечкә бил! — диләр.

— ВАТАНЫБЫЗ-З-З — киң болын,
Җиребез-з-з чиксез-з-з,— диләр,—
Бу болында без-з-з ялгыз-з-з,
Нишләрбез-з-з синсез-з-з! — диләр.

ГӨЛЛӘР дә тау битеннән
Болынга иелделәр.
Шаян җил кытыклагач,
Ак атка: «Бие!»— диләр.
Дөп, дөп, дөп, дөп! Дөпелдәп,
Тояклар биеделәр.

ДАВЫЛ чәчәкләре тын,
Тимәгез, давыл чыгар.
Давыл чәчәген өзеп

Узып китте юлчылар.

ЕЛАННАР чыжылдашып
Шуышалар үләннән.
Балыклар сикерешеп
Очып чыга күленнән.

ЖУМБА, авызын ерып,
Кояшка карап ала,
Коңгызлар, жуылдашып,
Үләнне тарап ала.

ҖИЛӘКЛӘР тирбәлешеп
Биешеп алалар да,
Гөл таҗларын бик матур
Ал төскә маналар да

ЗӘҢГӘР күлмәкле кызның
Керәләр учларына.
Шаян җилләр кагыла
Керфеге очларына.

ИҺИ! Искиткеч рәхәт!
Исәр җилләр шаярып
Иркәлиләр чәчләрен.
Сөртеп-сөртеп алалар
Кызның шатлык яшьләрен.

ЙӘ, бигрәк иркен болын!
Йоп-йомшак нурда коен!
Йөгәнсез ат сөенде,
Кызга килеп сыенды.

КУЛЫН тидерде кызчык
Ап-алсу борынына.

Уйлап куйды: «Бар да бар,
Җитми тик колын гына!»
Күбәләкләр җилфердәп
Кундылар колагына.

ЛҮС-ЛҮС юыртып, ак ат
Ләззәтләнеп чапты да
Болын түрендә туктап
Карап тора артына.

МАҢГАЕН сыйпый-сыйпый,
Яллары җилфердәшә.
Иһаһайлап кешнәде,
Тирбәлеп куйды рәшә.

НАЯН кызчык чәчәкнең
Суырды да нектарын,
Салып куйды чүәген,
Салып куйды оекларын.

ОЧКАК тузганакларга
Өргән иде әз генә,
Пәрәвезләр ябышты
Күзенә һәм тезенә.

ӨЙЛӘ дә җитә инде,
Кыз ашыкмый өенә.
Яңгырый тын болында
Җил уйнаган көй генә.

ПӘРӘВЕЗ очып йөри,
Күлдә балык сикерә,
Ак ат та биеп тора,
Тора алмый тик кенә.

РӘШӘГӘ чума-чума,
Кызчык суга иелде.
Су чебене, җемелдәп,
Кызчык янына килде.

СУГА сикерде кызчык,
Йөзеп китте тиз генә.
Күл үләне ябышты
Кызның коңгырт тезенә.

ТАБАН балык елмаеп
Кытыклады табанын.
Сизми дә калды кызчык
Каралганын һаваның.

УЕНЧАК ат кешнәде,
Кешнәде, күккә карап.
Исте яңгыр җилләре,
Бахбайның ялын тарап.

ҮКЧӘСЕН кыз камышка
Тидереп кенә алды да
Йөзде ак атка таба,
Тамчы тамды алдына.

ФӘРЕШТӘ чыкты ярга,
Сикерде тырк-тырк.
Ә һава аның саен
Каралды торып-торып.

ХИКМӘТ, ә! Кинәт кенә
Ишелеп төште яңгыр.
Зәңгәр күлмәк чыланды,
Чылангач бик кыендыр.

Бахбай! Бахбай! Кызны син
Түш астына сыендыр!

ҺАВАДАН су коела,
Коела, коен гына.
Уйлый кыз: «Эх, биредә
Юк бүген колын гына!»

ЦИРКТАГЫ күк иде,
Кызык иде көне дә,
Әрләннәр яшеренде,
Судан качып, өненә.
Җәелеп ята болын,
Кушлып яңгыр көенә.

ЧАЙКАЛА чәчәк, үлән,
Чайкала күлдә камыш.
Таныш бит, бик тә таныш
Бал корты канатына
Тамчылар тамган тавыш.

ШАБЫР-ШОБЫР тамчылар
Коела да коела.
Рәхәтләнеп, таралып,
Табигать су коена.

ЫЖЖЖЖ! Выжжжж!
Килә көчле җил,
Ыргыла күлдә дулкын.
Ыргыла атка таба,
Күрсәтә ярсу холкын.

ЭЧӘ ак ат тамчыны,
Җибәрә аннан кешнәп.

Чайкый да ул башкаен,
Үлән йота юешләп.

ЮЕШЛӘНДЕ бар җиһан,
Юллар әйләнде сазга.
Яланаяклы кызчык
Аптырап калды беразга.

Чүәге дә юпь-юеш,
Юпь-юеш күлмәге дә.
Юпь-юеш кызны ак ат
Әйтерсең күрмәде дә.
Атлады болын буйлап
Чишмәләр аккан якка.
Көмеш-көмеш тамчылар
Җем-жем итә тоякта.

ЯҢГЫР туктады инде,
Күпереп калды болын,
Һавадан алсу нурлар
Сузылды толым-толым.

Иһи! Искиткеч рәхәт!
Җылы җилләр кызчыкның
Иркәлиләр чәчләрен.
Сөртеп-сөртеп алалар
Кызның шатлык яшьләрен.

Күбәләкләр җилфердәп
Куналар колагына.

Иһи! Искиткеч рәхәт!
Бик рәхәт монда гына!
Җитми тик колын гына!

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)5
Б90

**Бәшәров Р. Г.**
Җәй кызы: Шигъри әлифба / Рәшит Бәшәр.— Казан: Мәгариф, 2007.— 23 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-7761-1711-4

Литературно-художественное издание
Для младшего школьного возраста

**Башар** Рашит
(**Башаров** Рашит Гафарович)

**Дитя лета**

Азбука в стихах

Казань. Издательство «Магариф». 2007

*На татарском языке*

Әдәби-нәфис басма
Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Бәшәр** Рәшит
(**Бәшәров** Рәшит Гафарович)

**Җәй кызы**

Шигъри әлифба

Редакторы *Л. Ә. Гыйззәтуллина*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Компьютерда биткә салучысы *Ф. К. Гомәрова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәмmәтова*
Корректоры *Г. Г. Мөхәммәтҗанова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.12.2007. Форматы 60х90 $^1/_8$. Офсет кәгазе. «Букварная» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 3,0. Нәшер-хисап табагы 3,21. Тиражы 2000 д. Заказ В-7/72.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
Email: magarif@mail. ru

«Дом печати» полиграфия-нәшрият комплексы.
420126. Казан, Ф. Әмирхан урамы, 12а.

ISBN 978-5-7761-1711-4

© «Мәгариф» нәшрияты, 2007
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2007